**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ К А Р А Р

от ___________ № __________

Бала туганда бер мәртәбә бирелә торган түләү турында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында туучылар санын арттыру чараларын көчәйтү максатларында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы Актаныш районында мөрәҗәгать итү датасына кадәр кимендә бер ел даими яшәүче хатын-кызларга өченче баласы туганда 30 мең сум, дүртенче балага 40 мең сум, бишенче балага 50 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләргә.

2.Татарстан Республикасы Актаныш районында даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер мәртәбә бирелә торган түләү бирү тәртибе турында кушымтада бирелә торган нигезләмәне расларга.

3.Татарстан Республикасы Актаныш районында даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер мәртәбә бирелә торган түләү турындагы мәгълүмат «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа"системасына урнаштырыла дип билгеләргә. Күрсәтелгән мәгълүматны «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа" дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыру (алу) "Дәүләт социаль ярдәме турында" 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары М.Ф. Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев

Татарстан Республикасы Актаныш
муниципаль районы Башкарма
комитет карары белән расланды
_______ __________2026 ел.

# Татарстан Республикасы Актаныш районында даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында мөрәҗәгать итү датасына кадәр кимендә бер ел даими яшәүче хатын – кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба-бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү).

2. Бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү түбәндәгеләргә бирелә: Татарстан Республикасы Актаныш районында мөрәҗәгать итү датасына кимендә бер ел даими яшәүче һәм хөкем ителүе булмаган хатын-кызга. Әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән хатын-кыз вафат булган, аның ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән (ата-ана хокукларында чикләнгән) очракта, бала туганда бер мәртәбә түләү баланың атасына (опекунына) бирелә.

3.Бала туганда бер мәртәбә бирелә торган түләүне алу хокукына әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе гражданнары, бала туу турындагы акт Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлегендә теркәлгән очракта ия була.

4. Бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү, әгәр мөрәҗәгать бала туган көннән соң алты айдан да соңга калмыйча килсә билгеләнә.

5. Бала туганда бер мәртәбә түләү балалары тулысынча дәүләт тәэминатында булган гражданнарга, ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән йә ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнарга, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булган гражданнарга билгеләнми.

## II. Бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү һәм бала туганда түләү тәртибе

6. Бала туганда бер мәртәбә түләүне билгеләү өчен әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә алар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр) Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенә бала туганда бер мәртәбә түләүне билгеләү турында банкта ачылган лицевой счет реквизитларын яисә башка кредит оешмасының (алга таба - гариза); вәкаләтле затлар өчен ышанычнамә күчермәсен; көнкүреш характеристикасын күрсәтеп гариза тапшыралар. Мөрәҗәгать итүчеләр гариза белән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документны күрсәтәләр. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгелән-

гән тәртиптә таныкланырга тиеш. Актаныш районында яшәү факты паспорт белән раслана.

7.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты ведомствоара гарызнамәләр нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге белешмәләрне ала: бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында; ана үлемен дәүләт теркәвенә алу турында; опека (попечительлек) билгеләү турында; ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү турында яисә ата-ана хокукларын чикләү турында; Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булмау турында, хөкем ителүнең булмау турында. Мөрәҗәгать итүчеләр үз инициативасы белән Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырырга хокуклы.

8.Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты гариза теркәлгән көннән алып ун эш көне эчендә бала туганда бер мәртәбә бирелә торган түләүне билгеләү турында яки аны билгеләүдән баш тарту турында күрсәтмә кабул итә һәм гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән күрсәтмә турында хәбәр итә.

9.Булган белешмәләр һәм (яисә) документлар нигезендә бала туганда бер мәртәбә бирелә торган түләү билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып аны алу хокукының булмавы тора.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

10. Мөрәҗәгать итүче тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар булган документларның дөреслеге өчен җаваплы

11.Бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне алу өчен кирәкле гариза һәм документлар (белешмәләр) турыдан-туры Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенә тапшырылырга яки почта аша җибәрелергә мөмкин.

12.Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне алучыларның шәхси эшләрен формалаштыра һәм саклый.

13. Бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

Татарстан Республикасы Актаныш
муниципаль районы Башкарма
комитет карары белән расланды
_______ __________2026 ел..

## КОМИССИЯ СОСТАВЫ*

| | |
|---|---|
| Бариев Илфак Шамил улы – | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Гыйлаева Миләүшә Зөфәр кызы _ | Оештыру бүлеге җитәкчесе, комиссия секретаре; |
| Вахитов Илшат Рәфит улы | Актаныш районы Советы Аппараты җитәкчесе |
| Әнвәрова Дилбәр Миркасыйм кызы – | Актаныш районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Сираева Лиана Рамил кызы – | Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары |
| Мөхәмәдиева Гөлфинә Баян кызы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының ГХАТ бүлеге җитәкчесе |
| Корбангалина Алиса Айрат кызы | Актаныш муниципаль районының "Финанс-бюджет палатасы" МКУ рәисе |
| Шәехова Илҗвира Марс кызы | Актаныш муниципаль районы Советының баш бухгалтеры |
| Сәрвәрова Наилә Фәрит кызы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлек җитәкчесе |
| Хаев Айдар Рәфгать улы – | «Актаныш үзәк район хастаханәсе " ДАССУ баш табибы |
| Басыйров Булат Мөзәллиф улы – | РФ пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бүлекчәсенең Актаныш районындагы клиент хезмәте җитәкчесе (төркем хокукларында) |
| Хуҗахметова Гөлназ Фирдәвис кызы – | -Актаныш муниципаль районында Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы |
| Мөхәмәтдинов Илнар Тәлгать улы – | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы ; |
| Шакирова Раниза Митҗан кызы – | Актаныш муниципаль районының "Мәгариф идарәсе" МКУ башлыгы; |

*Искәрмә: Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган комиссия әгъзалары комиссия составына килешү буенча кертелә